Нырье авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2016 елның 18 гыйнвары № 3

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге**
**Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 21 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итү, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 16 – 19 нчы пунктларны өстәргә:

«16) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга

юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү.»;

2) 33 статьяның 1 өлешендә:

38 пунктта түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«, Мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру»;

3) 41 статьяда:

2 өлештә «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен өстәргә;

4) 49 статьяда:

а) 1 өлешнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

« - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итә.»;

б) 1 өлешнең 6 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруны тәэмин итә;»;

в) 1 өлешнең 6 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;»;

г) 1 өлешнең 7 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

д) 1 өлешнең 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

« - җирлек халкының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыра, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итә.»;

е) 1 өлешнең 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

« - милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра.»;

ж) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

« - җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карау чараларын тормышка ашыра.»;

5) 69 статьяда:

түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлешен өстәргә:

«2.1. Җирлек башлыгы тавышы җирлек Советы карарларын кабул иткәндә җирлек Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына»;

6) 79 статьяда:

2 өлештә «аларны акчалата тоту чыгымнары» сүзләрен «аларның хезмәт өчен түләү чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга»;

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев